# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
Коноваловка авыл җирлеге составына кергән Тупач торак пунктында
халык җыены нәтиҗәләре турында

**21.11.2020ел.** **№6**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 14 ноябрендә узган халык җыены нәтиҗәләре белән халык җыенының йомгаклау беркетмәсе түбәндәге мәсьәлә буенча төзелде: "2021 елда Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Коноваловка авыл җирлегенең Тупач торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә Сез ризамы?":

- Тупач торак пунктында чишмә яны территориясен төзекләндерү (вак таш сатып алу, грейдерлау, төзелеш материаллары сатып алу, павильон урнаштыру, керү юлы ясау, эшләр өчен килешү нигезендә түләү);
- Тупач торак пунктында җәйге чорда территориянең үләннәрен чабу (эшләр өчен килешү нигезендә түләү).

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган катнашучылар исемлегенә 182 халык җыенында катнашучы кертелгән, халык җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны - 104 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
җыенда катнашкан 104 кеше «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар бирде:

1.Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Коноваловка авыл җирлегенең Тупач торак пунктында халык җыены узуын танырга, халык җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. "2021 елда Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Коноваловка авыл җирлегенең Тупач торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә Сез ризамы?" мәсьәләсе буенча карарны танырга һәм түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтергә:

- Тупач торак пунктында чишмә яны территориясен төзекләндерү (вак таш сатып алу, грейдерлау, төзелеш материаллары сатып алу, павильон урнаштыру, керү юлы ясау, эшләр өчен килешү нигезендә түләү);
- Тупач торак пунктында җәйге чорда территориянең үләннәрен чабу (эшләр өчен килешү нигезендә түләү).

3. Коноваловка авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән халык җыены нәтиҗәләрен кабул ителгән көннән 7 көн эчендә Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында (https://menzelinsk.tatarstan.ru) хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Коноваловка авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

**Халык җыенында рәисле итүче,**
**Минзәлә муниципаль районы**
**Коноваловка авыл җирлеге Башлыгы** **С.Ә. Билалова**